ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦПАЛЬ РАЙОНЫ
БОЕРГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

**КАРАР**

“29” август 2019 ел Боерган авылы № 15

**“2019 елның 1 яртыеллык өчен Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап проекты буенча халык тыңлауларын үткәрү хакында”**

Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге халкының «2019 елның 1 яртыеллык өчен Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап» хакында карар проекты буенча фикер алышуда катнашу хокукларын саклау максатыннан, Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлегендә халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә таянып

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «2019 елның 1 яртыеллык өчен Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап» хакында Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Советы карар проекты буенча халык тыңлауларын үткәрергә.
2. Әлеге карарны авыл җирлегендә мәгълүмати стендларда һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районның хокукый мәгълүмат рәсми порталында 2019 елның 29 августтан да соңга калмыйча урнаштырырга.
3. Билгеләргә
3.1 үткәрү вакытын – **2019 елның 06 сентябрендә 10.00 сәгатьтә**;
3.2 үткәрү срогын – 1 көн;
3.3 үткәрү урынын – Тукай районы, Боерган авылы, Тынычлык урамы, 64 Б йорт (Башкарма комитет бинасы);
3.4 фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тәкъдим итү, чыгыш хокукы белән халык тыңлауларында катнашу өчен гаризалар бирү адресы – Тукай районы, Боерган авылы, Тынычлык урамы, 64 Б йорт(эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатька кадәр);
3.5 чыгыш ясау хокукы белән халык тыңлауларында катнашу өчен гаризалар бирү вакыты 2019 елның 05 сентябренә кадәр (тел.37-78-23).
4. Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Башкарма комитетына билгеләнгән тәртип нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда «2019 елның 1 яртыеллык өчен Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап» хакында карар проекты буенча халык тыңлауларын әзерләргә һәм үткәрергә.
5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Боерган авыл җирлеге Башлыгы З.М.Камилҗанов

Совет БИЮРГАНСКОГО сельского поселения